**Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы**
**Федотовка авыл җирлегенең Федотовка торак пунктында**
**гражданнар җыены**
**КАРАРЫ**

2023 елның 18 ноябре №2

2024 елда Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының Федотовка авыл җирлегенең Федотовка торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм файдалану турында

Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Лениногорск муниципаль районы Федотовка авыл җирлеге Федотовка торак пункты гражданнар җыены КАРАР БИРДЕ:

1. 2024 елда үзара салымны Лениногорск муниципаль районының Федотовка авыл җирлеге Федотовка торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, 1 төркем инвалидлардан; сугыш хәрәкәтләре ветераннары; Бөек Ватан сугышы һәм сугыш хәрәкәтләре ветераннарының тол хатыннары; көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлар, хәрби хезмәт үтүче гражданнардан тыш, һәр балигъ булган кешедән 300 (Өч йөз) сум күләмендә кертергэ.

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерергә:

1.)Торак пункт территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау, аларның үтәлешен контрольдә тоту, күрсәтелгән кагыйдәләргә ярашлы рәвештә торак пункт территориясен төзекләндерүне оештыру:

-МТЗ-82.1 тракторын тоту һәм хезмәт күрсәтү(ягулык-майлау материаллары сатып алу, плуг сатып алу )

- тракторчы хезмәтенә килешү буенча түләү ( территорияне коры һәм чүп үләненнән чабу, кардан чистарту, полосаларны минеральләштерү һәм сукалау һәм башка эш төрләре)

2.) Торак пунктлар чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге

Яңа, Түбән, Таулы, Югары, Күл урамнарында вак таш белән капланган юлларны чокырлы ремонтлау (таш сатып алу һәм ташу)

3.) Торак пунктлар чикләрендә янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү;

- янгын гидрантын урнаштыру

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Федотовка авылы, Совет урамы, 6 йорт, Совет урамы, 8 йорт (мәдәният йорты бинасы), Кузьминовка авылы, Кооператив урамы, 10 йорт (клуб бинасы) адресы буенча урнашкан махсус җиһазландырылган мәгълүмат стендларында игълан итәргә, Лениногорск муниципаль районы рәсми сайтында (http://leninogorsk.tatarstan.ru) «Авыл җирлекләре» бүлегендә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru/)кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Лениногорск муниципаль районы
«Федотовка авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге башлыгы В.И.Павлова